**ГЛАВА**
**Терсинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Тирсә авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2022 Тирсә авылы № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге башлыгы к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2022 елның 28 октяберендә 11 сәг 00 мин билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2022 елның 28 октяберендә 13 сәг 00 мин билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 3 этабын 2022 елның 28 октяберендә 15 сәг 00 мин билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 4 этабын 2022 елның 28 октяберендә 18 сәг 00 мин билгеләргә.
5. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Тирсә авылының Восточная, Восточный тык., Яшьләр, Первомайская, Мәктәп, Заречная, Набережная, Нагорная урамында яшәүчеләр.

-2 этап: Тирсә авылының Үзәк урамында яшәүчеләр.

-3 этап: Тирсә авылының Полевая, Дуслык, Тынычлык, Луговая, Озерная, Садовая, Совет, Хезмәт урамында яшәүчеләр.

-4 этап: Тирсә авылының Вокзал урамында яшәүчеләр.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Тирсә авылының юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю;
2. Урам юлларына хезмәт күрсәтү, карны чистарту;
3. МТЗ-82 тракторына ГСМ сатып алу, һәм тракторчының хезмәте өчен түләү;
4. Тирсә авылы мәдәният йорты өчен көчәйтү - акустик системасы сатып алу;
5. Урамнарны яктырту өчен электр товарлары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тирсә авылы, Үзәк урам, 163, авыл мәдәният йорты янында үткәрергә.

8. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

9. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

11. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Б. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН